КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 12 май г.Казань № 691

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Безнең йорт – Татарстан» республика этномәдәни фестивале турында» 2023 ел, 21 ноябрь, 1495 нче карары белән расланган «Безнең йорт – Татарстан» республика этномәдәни фестиваленең лауреатлары дип танылган кайбер башкаручыларны һәм (яки) иҗат коллективларын аларның матди-техник базасын ныгыту юлы белән бүләкләүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү өчен коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Безнең йорт – Татарстан» республика этномәдәни фестивале турында» 2023 ел, 21 ноябрь, 1495 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 ел, 30 декабрь, 1250 нче; 2025 ел, 26 декабрь, 1160 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «Безнең йорт – Татарстан» республика этномәдәни фестиваленең лауреатлары дип танылган кайбер башкаручыларны һәм (яки) иҗат коллективларын аларның матди-техник базасын ныгыту юлы белән бүләкләүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү өчен коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктта «шулай ук физик затларга – товарлар, эшләр, хезмәтләр җитештерүчеләргә» сүзләрен «физик затларга» сүзләренә алмаштырырга;

5 пунктта татар текстында «мәгълүмат» сүзеннән соң «субсидия бирү өчен бюджет ассигнованиеләре Министрлыкка җиткерелгән көннән соң килә торган көннән алып 10 эш көне эчендә» сүзләрен өстәргә;

48 пунктта «исәп-хисап яисә корреспондент» сүзләрен төшереп калдырырга;

54 пунктта татар текстында «Бирелгән субсидия» сүзләрен «Субсидия акчасы» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин